| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

« 31 » марта 2020 с. Тюлячи № 73

Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дежур төркемнәр оештыру турында

МКУ «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» нең 2020 елның 27 мартындагы 105 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә эш көне булмаган көннәрне игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указы нигезендә,

1. 2020 нче елның 30 мартыннан 3 апреленә кадәр Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә мәктәпкәчә төркемнәр эшчәнлеген вакытлыча туктатып торырга.

2. Ата-аналар гаризасы буенча, халыкның нормаль тормыш шартларын тәэмин итү максатларында, Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә, ата-аналарына «Россия Федерациясендә эш көне булмаган көннәрне игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указы кагылмаган, балалар өчен дежур төркемнәр оештырырга.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н. Н. Хаҗипов